Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының "Чиябаш авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
Советы карары белән кабул ителде
2025 елның «08» августы № 135

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**«Чиябаш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр кертү турында**

Рус Чиябаш ав.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Чиябаш авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Шибашинского**
**сельского поселения**
**Алькеевского муниципального**
**района**

422886, ТР, Рус Чиябаш авылы,
Тынычлык урамы, 20 й.
Факс (84346) 75-4-37

422886, РТ, Алькеевский район,
с. Русские Шибаши, ул.Мира, д.20
Факс (84346) 75-4-37

РЕШЕНИЕ Рус Чиябаш ав. КАРАР

2025 елның " 08 " августы № 135

Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 81-нче номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 81-нче карары белән (29.07.2024 елның 106-нчы карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Чиябашы авыл җирлеге территориясендә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Рус Чиябашы авылы, Тынычлык ур., 20 йортта (җирле үзидарә), Рус Чиябашы авылы , Тынычлык ур., 20 йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Чиябаш авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М. К. Хисмәтов

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 135

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:
"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".